КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 май г.Казань № 609

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче; 2022 ел, 5 май, 417 нче; 2022 ел, 16 май, 446 нчы; 2022 ел, 7 июль, 651 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның бишенче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарында билгеләнгән тәртиптә балага ай саен бирелә торган пособие алучылар булган, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләр балалары» сүзләрен «бала туугa һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә ай саен бирелә торган пособие алучы гаиләләрнең 17 яшькә кадәрге балалары» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүче балалар һәм социаль

куркыныч хәлдәге гаиләләр балалары, психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында тәрбияләнүчеләр реестрын Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына кертүне тәэмин итәргә.»;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җәйге чорда Кара диңгез ярында шәһәр яны ял лагерьларында профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлешләрдәге сменаларда катнашучылар составына кертү өчен иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар исемлеген Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына җибәрүне;»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бала туугa һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә ай саен пособие алучы гаиләләрнең 17 яшькә кадәрге балалары;»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы җәйге чорда Кара диңгез ярында шәһәр яны ял лагерьларында профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлешләрдәге сменаларда катнашучылар составына кертү өчен иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар исемлеген формалаштыра.»;

11.2 һәм 11.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ай саен социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүче балалар һәм социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр балалары, психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортларында тәрбияләнүчеләр реестрын Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына кертә.

11.3. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары, Социаль тәэмин ителешнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүматтан файдаланып, бала туугa һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә ай саен бирелә торган пособие алучы гаиләләрнең 17 яшькә кадәрге балаларының җыелма исемлеген төзи.»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча ведомствоара комиссия составында:

комиссия составыннан А.М.Минголовны, Т.Д.Сөләймановны, Г.Р.Шакированы чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары Денис Владиславович Лулаковны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы урынбасары Александр Васильевич Мищихинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары Алмаз Әзһәр улы Хөсәеновны;

Раушан Булат улы Зариповның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы»;

Ринат Наил улы Садыйковның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары».

2. Бу карарның 1 пунктындагы беренче – унбишенче абзацлары гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин